САГЫШЛЫ ЯЗМЫШ

Муниципаль мәдәни казна учреждениесе
Үзәкләштерелгән Малмыж китапханә системасы
Г. Тукай исемендәге Иске Йөрек авыл китапханәсе –
татар мәдәни үзәге

САГЫШЛЫ ЯЗМЫШ

Иске Йөрек
2017

Төзүчесе
Е. Н. Касимова

Компьютерда җыючы
Е. Н. Касимова

Чыгарылыш өчен җаваплылык
М. Т. Хасанова

12 +

Сагышлы язмыш : истәлекләр / төз. Е. Н. Касимова, җаваплы ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : ММКУ Малмыж ҮКС, Г. Тукай исемендәге Иске Йөрек КФ, 2017.- 24 б.

Җыентыкка Сагитова Бәлхия апа сөйләгәннәреннән сугыш һәм хезмәт кырларында, сынаулар алдында сынып калмыйча, тормышта үз юлларын таба алган әти-әнисе турында истәлекләр тупланды.

Судьбы печальной отголоски : воспоминания / сост. Е. Н. Касимова, ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : МКУК Малмыжская ЦБС, Староирюкская СБФ – центр татарской культуры им. Г. Тукая, 2017. – 24 с. – (В Победе их немалая заслуга).

Выпуск издания реализован в рамках проекта «Живая легенда». Финансовая поддержка проекта осуществлена благотворительным фондом «Хорошие истории» в рамках программы «Активное поколение».

©ММКУ Малмыж ҮКС, 2017
Т. 15 экз.

Охшаш язмышлар

Әче язмышлар. 1941 – 1945 һәм аннан соңгы еллардан бүгенге көнгә кадәр дәвам итүче әче, охшаш язмышлар... Бу охшаш язмыш ияләре – бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар, тыл ветераннары, сугыш чоры балалары безнең арабыздан китеп баралар. Алар турындагы хатирәләрне барлау, җыю, саклау һәм үзебездән соңгы буынга җиткерү – безнең изге бурыч. Ничәмә – ничә еллар узса да, күп буыннар берсен – берсе алыштырса да, ватандашларыбызның батырлыгы һәрчак күңелләрдә саклана. Бөек Җиңү көнендә хатирәләр барлана, тыныч тормышыбызга, аяз күгебезгә тагын бер кат шөкер кылабыз.

Бу җыентыкка кергән истәлекләребезнең шаһитлары - геройлар да түгел, үтәдән тыш батырлык кылучылар да түгел, алар – бердәнбернең, дистә, йөз, меңнең, миллионның арасыннан берсе – иң кадерлесе, иң кирәге, иң якыны, иң сөйгәне. Бу истәлекләрне безгә бәян итүчеләр үзләре дә, әче язмыш җилләре белән сугылган. Аларның язмышлары да, сагышлары да яшь аша. Җыерчыклар белән чарланган йөзләре буенча тәгәрәгән күз яшьләре әле тиз генә кипмәс, хәтер дәрьялары бик озак саекмас.

.

Аерылып төшкән бәбкә.

Әниемне күз яшьләрсез искә төшерә алмыйм. Язмышының корган сынау челтәреннән арынып, тормышта үз юлын таба алуы, үзенә күрә бер соклану хисе тудыра.

Әниием, Рауза – чәчәклек, гөл бакчасы, җәннәт бакчасы исеме иясе булса да, тормышын, гел оясыннан аерылып төшеп калган бәбкә итеп тоеп уздырды. Хәер, моның сәбәбе дә юк түгел иде. Әниием гаиләдә олы бала булып 1904 елның, урак өстендә Яр Чаллы ягындагы Татар Пәнәче Башы авылында дөньяга килә. 1904 елда бишектә яткан бу сабый инде 1914 елда, нибары 10 яшендә, үз канаты астына 6, 3 һәм 1 яшендә булган туганнарын җыйнап, тулы ятим булып кала. Әнисе җәйге урак өстендә, ә әтисе көз көне, кешеләр гөрләшеп каз өмәләре уздырган чакта, вафат булалар. Җырларда

җырланганча, әтисез бала да үлми, дөнья рәхәтен дә күрми, ә әнисез дә калган балага кайда дөнья рәхәте тигән? Менә ул кайда тормышның мәхшәре, менә ул тормышның явыз челтәре. Әти – әнисе үлгәннән соң аларның тормыш йөген тартырга әтиләренең энеләре ярдәмгә килә. Бер энесе, исеме хәтердә түгел инде, бигрәк тә йомшак, киң күңелле, туганчыл була. Ул абыйсының балаларының тормышын кайгыртып, ярдәмләшеп яши. Тик бәхетсезгә вакытсыз дигән кебек, бу абыйлары ятимнәрне тагын да ятимләтеп, вакытсыз авыртудан дөньядан китеп бара. Туганы үлгәннән соң, икенче абыйлары, белмим кеше сүзеннән читенсенеп, белмим аларның булган маллары хисабына үз тормышын бөтенәйтү исәбе белән, ятимнәрне үз йортына алып кайта. Әниемнәр әти – әнисеннән ярлы калмыйлар, йортлары да, ул чор өчен, таза йорт , атлары, сыерлары, тавыклары була. Бу йортына алып кайту, дөресрәге, бусага уздыру гына була. Баларга урын ишек катында, бусага янында билгеләнә. Бусага янындагы суык, тараканнарның кыштырдавы, туяр – туймас ашау ятимнәрнең сабырлыгын сындыра. Әнием туганнарын җитәкләп, абыйсының йортын калдырып, үз нигезләренә кайтып китә. Балалар кайтып китә, тик аларның ата – аналарыннан калып, үзләре белән килгән мал – туар берсе дә кире кайтмый, абыйларының мөлкәте булып кала. Ләкин, синең мал – мөлкәтен бармы - юкмы, тормышында таянычын бармы – юкмы, дөнья тәгәрмәче әйләнүдән туктамый, ул аяусыз тәгәрәвүен белә. Әнием дә үзенннән кече туганнары белән тормыш нужасын әкренләп тарта бирәләр. Ягарга утын булмаганлыктан үзәк өзгеч суык, ашарга җитмәгәнлектән, күкрәк астыннан сулык – сулык итеп

торган бер халәт –күздән йокыны тартып алып кына калмый, дөньяның шыксызлыгын, ятимлекнең көчсезлеген кабат – кабат искә төшереп тора. Ул елларны кичергән кыерсыту – кимсетүләрне әнием бер бетмәс коточкыч төш кебек искә ала иде. Бигрәк тә революциядән соң, властька я аклар, я кызыллар килгән вакытлар яман иде ди. Туганнарының комсомол булулары да үзенә күрә кыенлыклар тудырган. Кунарга кергән кызыл отряд солдатының, фәлән мулланы суеп аттым әле дип, үткен, озын хәнҗәреннән тамган кан тамчыларының күз алдыннан китәсе юк. Никадәр авыр булса да тормыш әкренләп алга бара, әнинең бер сеңлесе Алабугада укытучылыкка укырга керә. Шушы чорда әниемнәрнең йорт – җирләре янып бетә, бераз колхоз ярдәме белән алар йорт җиткерәләр. Тик бу фаҗигадан тернәкләнә алмыйча азапланганнан соң, читкә әнинең туганнары янына Карело – Финск ССРга күчеп китәләр. Анда тормыш әзме – күпме уңайрак була, өс – башлары бөтенәеп, тамаклары туйган кебек була. Сугыш башланганда да әнием шунда була, әтием белән очрашулары да, туган якларыннан ераста чит җирләрдә була.

Әтием – Хайруллин Гиният 1912 елның мартында туган булса да, читкә китеп эшләр өчен үзенең яшен күбәйтеп, 1910 елда туган итеп язу алган. Ул вакыт өчен бу гадәти хәл булган.

Гаиләләр күп балалы булганлыктан, кыюрагы кая да булса китеп, акча эшләп кайту, туганнарына булышу ягын караган. Авыл җирендә, колхозларда хезмәт көненә (трудодень) эшләү булган, хезмәте өчен акча юнәтә алган кеше бик булдыклы саналган. Чит җирләрдә гаилә корып, тормыш башлап җибәрәләр.

Яшь гаилә әтинең туган авылына кайтып дөнья күрүне дәвам итә. Авылда тормыш җиңелләрдән булмый, өч балалы гаилә янә 1940 елның 19 августында Карело – Финск ССРына күчеп китә.

Справка.
гражд. Хаирулинину Гатияту
в том, что он переселяется
в Карело-Финскую ССР. отправка 19/VIII-40 г.
17 августа 1940 г.
Председат. Фатих

Бөек Ватан сугышы башлана. Бу сугыш башлану күпме кешеләрнең язмышына күз яше, кайгы – хәсрәт китерә. Әтием дә сугышка алына.

Ул сугышка алынганда әнием берсеннән – берсе кечкенә өч бала – 1934 елгы Самат абыем, 1937 елгы Фагыйлә апа һәм 1940 елгы Фаяз абыем белән кала. Сугышның беренче көннәре илбасарларның әсәрләнә – әсәрләнә сугышкан чорлары, көненә берничә мәртәбә самолетлардан снарядлар атып, бомбалар ташлап торалар. Төтен, тузан, снаряд кыйпылчыклары аша кояш нуры да үтеп керә алмаслык хәлдә кеше җан асраган. Тамак туйдыру турында уйлау да мөмкин булмый, шушы хәлдә аларны эшелоннарга төяп бу җирдән чыгарып җибәрәләр. Әтиемнең туган авылына исән – сау кайтып җитү, үзе бер могҗизага тиң булды, дип исенә төшерә иде әнием. Сугышның бөтен снаряд – бомбалары без кайта торган эшелон өстенә генә төбәлгән кебек иде. Вагонннарга кереп урнашырга җитешмибез “Воздух” командасы янә яңгырый, җыйнаулашып җиргә сыенабыз. Самолетларның гүләве, кычкырыш, елау, яралганнарның ыңгырашуы – сугыштан соң күп еллар әле колактан китмәде, дип искә ала иде әнием. Әтиегезнең туган авылына кайту да бәхет өстәмәде. Торырга өй юк, ягарга утын, ашарга ризык – нәрсәгә кагылсаң, шул юк. Ул еллардагы юклыкны, авырлыкны искә алганда да һуштан язарлык. Бер үзе чит – ят җирдә, бер туган, бер якын кеше юк. Әтиемнең әнисе – Гайшәбану әби дә киленең үз итәсе килмәгән, җай чыккан саен кимсетү, кыерсыту ягын караган, югыйсә авырлыкларны җиңәргә бергә – бергә уңайрак булыр иде. Әтиебез җиңү өчен үзен аямыйча сугышканда өйдә низагланып утырып булмый, чөнки бөтен ир – ат эше дә, балалар карау, тормышның дилбегәсен тарту хатыннар һәм балалар кулында

булган. Сирәк булса да фронттан килгән хатлар тормышка ямь өстәгән, өмет уяткан, дәрт биргән.

Әтиебез сугышта өч тапкыр зур яралану алып, госпитальләрдә ятып чыккан. Беренче ярасы – снаряд кыйпылчыгы эчен үтәли тишеп чыга. Бу яраланудан Грузиянең Тифлис шәһәрендә дәвалана.


Справка о ранении
В боях за Социалистическую Родину
№ 2465
Груз. ССР
НАРКОМЗДРАВ
ЭВАКОГОСПИТАЛЬ
№ 2465
Тов.
194 г. был
194
№
Тел №
Нач. госпиталя

Икенче ярасы – башында, дәвалану Ленинград госпитальләренең берсендә, блокада чорына туры килә. Ул вакытта баштан узганнарны искә алу да коточкыч, дип сөйли иде әтиебез. Госпиталь стеналары ап – ак кар белән катып тора иде, үзебезне ниндидер базга ташланган кебек хис итә идек... Андый салкында нинди дәвалану булсын инде ул...Шушы сүзләрдән гайре башкаларын искә алу булмады. Сугыш турында да бик әз генә сөйли иде. Берничә мәртәбә чолганышта калып, командирлар, бик күп сугышчылар үлеп бетте. Исән калган иптәшләр белән, бер – беребезгә ярдәмләшеп, чолганыштан шактый гына дошманнарны юк итеп, чыктык. Күп коралдашларыбыз билгесез югалган кебек, безнең бу эшләребез билгесезлеккә чумды. Хөкүмәтебез

тарафыннан бернинди бүләкләү, рәхмәт сүзе ала алмадык, чөнки безнең батырлыкларыбызны дәлилли алучы командирларыбыз һәлак булдылар. Күп чакта, төнлә, немец солдатлары йоклаган вакытта - кинәт, көтелмәгән һөҗүмнәр ясый идек. Һөҗүм башлангач ак кальсоннары белән чыгып сибеләләр иде алар. Мондый һөҗүмнәр вакытында без аптыраган эш, немец солдатларының өс киемнәрен салып, ак эчке киемнәр белән йоклаулары, чөнки мин үзебезнең өс киемен салып йоклаганны хәтерләмим дә. Хәер, безнең өс киемнәрен салып йокларга түгел, алыштырып киергә дә алмашы юк иде. Сугышка чакырылгач, бирелгән киемнәрнең нидән торганын күрсәң, аптырап калырлык. Әле ул киемнәр яңа түгел, барсы да 20 - 30 % таушалган. Менә беркетнәмәгә теркәлгән әйберләр – фуражка – 1, җәйге пиджәк -1, күлмәк -1, чалбар – 2, эчке күлмәк – 2, эчке чалбар -1, трусик – 2, майка – 2, гәлүш – 1, сөлге – 1, носки – 2. Бу беркетнәмәнең бүгенге көнгә кадәр саклануы да хәйран искиткеч.


ОПИСЬ (квитанция) 1068

Наименование предметов

Шапка
Кепка
Фуражка
Пальто зимнее
Пиджак летний
Рубаха верхняя
Брюки верхние
Рубаха нательн.
Кальсоны нательн.
Трусы
Майка
Ботинки
Сапоги
Носки

Всего предметов

Расписка в получении вещей

Әтием өчен дә, әнием өчен дә хатирәләрне яңарту – төзәлә башлаган күңел яраларын кузгатуга тиң булды. Дәваланып чыкканнан соң әтием гаиләсе янына кайтып киткән. Ул кайту сөйләп бетергесез зур сөенеч булган. Мин үзем 1943 елда туганмын һәм әтиемнең өченче мәртәбә яраланып, Кировта госпитальдә дәваланып кайтуында, беренче соравы: “Бу безнең баламы?” булган. Бу 1944 ел була, әтием кулы яраланып, хәрәкәтләнә алмый торган булып калгач, сугыштан өйгә кайтарылып җибәрелә.


ВЦСПС
УПРАВЛЕНИЕ ГОСПИТАЛЕЙ
ЗВАНОГОСПИТАЛЬ
№ 4017
27 Апр 1942 г.
№ 30/5-13

СПРАВКА.

Настоящая выдана Гр-ну Хайрулину Г. Г., происходящему из Кировской области, Малмыжского района, Ирюнского с/сов. деревни Ирюн, в том, что он мобилизован Малмыжским Р.В.К. города Малмыжа в 194.. г. месяце, в настоящее время он находится на излечении в госпитале № 4017 в г. Кирове.

Справка выдана для возбуждения ходатайства его семьей на получение пособия.

Военком госпиталя № 4017 г. Кирова

/Сметанин/


Свидетельство № 39
(БЕССРОЧНОЕ)
(Хранить вместе с военным билетом)
Об освобождении от воинской обязанности

Выдано настоящее свидетельство Елабужским РВК Татарской АССР военнообязанному 1910 года рождения Хайрулин Гиниятт (фамилия, имя, отчество) Ирюнского состава запаса Первой категории ВУС № 1 уроженцу Кировской обл. Малмыжский р-н д. Ирюн Ирюк

в том, что он по освидетельствованию 17 марта 1948 года комиссией при Елабужском РВК Лен. обл. признан негодным к настоящей воинской обязанности с исключением с учета по гр. Б 116, 46 болезней приказ НКО СССР 1942 г. 336 в связи с воинского учета.

Подлежит перерегистрации через

17 марта 1948.

КРАТКИЕ СВЕДЕНИЯ О ПРОХОЖДЕНИИ СЛУЖБЫ В СУХОПУТНЫХ ВОЙСКАХ, ВОЕННО-ВОЗДУШНЫХ И ВОЕННО-МОРСКИХ СИЛАХ, ПОГРАНИЧНЫХ И ВНУТРЕННИХ ВОЙСКАХ МВД

1944 елны 4 яшендәге Фаяз исемле абыем ачтан үлә. Әнием аны йөрәк сыкравы белән искә ала иде: “Шул баланы саклап кала алмадым, әтисенең кайтканын бик көтте. Әти кайтканда безгә сохари, шикәр, балык алып кайта ди. Әтисе кайтты, Фаязым көткән сохари, шикәр, балык та кайтты, тик сабыем ул ризыкларны ашап исән кала алмады инде, сабыемның күзләре мәңгегә йомылды”. Абыем үлеменнән соң, әти белән әни безне алып, юкны төйнәп авылдан Украина якларына чыгып китәләр.

Украина фашистлардан азат ителгән була, без Шапитовка дигән җиргә барып урнашканбыз. Ул чорда анда туклык булган, чөнки фашистлар басып ала башлагач кешеләр үзләренең бөтен әйберләрен ташлап киткәннәр. Базларда капчык – капчык бәрәңге, алма һәм башка ризыклар бик күп булган. Эшкә йөргәннәр – чүп утарга, басу ниндидер елга аркылы чыгып (елганың исеме хәтердә түгел) йөри торган булган. Тамак тук булгач эшнең авырлыгы сизелмәгән кебек. Барып урнашкан елның икенчесендә әтине кибет каравылчысы итеп эшкә куйганнар. 1946 елны сеңлебез Фәния дә туган. Тик мондагы уңайрак тормыш та озак сузылмый, сугышның ачлык дигән афәте килеп җитә: йогышлы авыртулар, ачтан шешенеп үлүләр... Бу авырлыклар үзәккә үткәчтер инде, әтием белән әнием Ленинград өлкәсенең Сланцы шәһәрендә яшәүче әниемнең сеңлесе Мөсәвәрә, энесе Әгъләмтиннең чакыруы буенча алар янына күчеп китәләр.

Сланцы шахтерлар шәһәре була. Анда тормыш бераз уңайрак, эшчеләр акча алып эшли, кибетләрдән нидер булса сатып алырга мөмкинчелек бар. Әтием “Черновской лесопункт” дигән оешмага, урман кисү

эшенә урнаша. Әниебез башта урман эшенә урнашкан иде, соңгарак аны машиналарны йөртү өчен яга торган шүрәкәләр ярып, бер – берсе бер кубометр сыешлы әржәләргә, тутырып торырга куйдылар. Тормышыбыз әкренләп бөтенәя башлый. Безнең яшелчәләр утыртырга җиребез, кәҗәбез, тавыклар, йорт куяннарыбыз бар иде. Балалар барыбыз да көчебездән килгән кадәр хуҗалыкта эшләп, ярдәмләшеп яшәдек. 1950 елларда инде без тамак туклыгы өчен генә түгел, каралты – кура, өс – баш бөтенәйтү турында да уйлый ала идек. Өскә киергә пәлтә, плюш, икешәр пар лаклаган резина итек, мәктәпкә киергә форма күлмәкләребез бар иде. 1950 елны мин үзебез торган җирдә 1нче класска укырга кердем. Анда башлангыч мәктәп кенә булганлыктан, 5 класска укырга Сланцы мәктәбенә бардым. Шул истә калган: “Мәктәп зур, ике катлы. Безне бер класска кертеп утырттылар, беренче партада утырганга укытучы такта сөртә торган чүпрәкне чылатып килергә җибәрде, ә мин адаштым. Кая барырга белмичә, классымны таба алмыйча еладым”. Укуым әйбәт булды, математика укытучыбыз бик көчле булганлыктан, бу фән минем яратканнар исәбендә булды. Бу фәнне, сугышта катнашып контузия алган, яралану нәтиҗәсендә уң кулы зәгыйфләнеп калган Анна Степановна укытты. Күз алдыннан аның сул кулы белән тактага язуы, ә шул вакытта кара перчатка киертеп куйган уң кулының асылынып торуы китми. Шулай тормышыбыз да җайлаша башлады, әтиебез эшеннән ял алып, сеңлебез Фәния белән туган авылына кайтып китте. Туган илендә әнисе Гайшәбану улын читтә калдырасы килмәгәнен белдереп караса да, әти тиз генә торган җирен ташлап кайтырга риза

булмаган. Гайшә әбиебез әти белән бергә кунакка килеп, бездә бер кышны торып чыкты. Кунакка килүнең нигезе, безнең тормышны күреп һәм ничек булса да безне Йөреккә алып кайту нияте булган. Әби үз теләгенә ирешті 1955 елның май аенда, мин 5 классны тәмамлагач, без янә җыенып юлга чыктык, әтинең туган авылы, туган нигезенә. Әнинең күченеп йөрү теләге юк иде, кайтмаска карышып карады, ләкин әти кайту карарына килгән иде инде.

Юл газабы – гүр газабы дигәннәр бит, бик күп авырлыклар кичереп, әтинең туган нигезенә кайтып җиттек. Авылда ул елларда әле халык сугыш китергән афәтләрдән, юклыктан, ачлыктан арына алмаган иде. Тормыш бик авыр, безнең элеккеге торган җиребез бик күп алда иде. Монда торырга өй юк, утыртырга бакча юк – тормышның авырлыгын әйтеп бетерә торган түгел. Әтиебез ат караучы булып урнашты. Ат абзары, хәзерге Зиатдинов Равил өе урынында, балчыкка салам кушып күтәргән стеналы иде. Сугыштан соңгы еллар, бөтен эш ат көче белән эшләнгәнгә, атлар әз түгел, шуңа әтиебез мәш килеп күп вакытын атлар янында уздыра иде. Озак еллар каешчы, сбруйлар рәтләп торды (шорник). Үз эшен әтиебез бик теләп башкарды, янәшәдәге күрше рус авылларына: Яңа Кубыр, Иске Кубырга да барып хезмәт куйган. Бу эшләр әтигә авыр була башлагач, аны каравыл торырга күчерәләр. Сугышта алган яралар үзләрен белдерми тормый, әтинең тазалыгы нык какшаган була. Әтиебезнең тешләре цинга авыртуы нәтиҗәсе – коелып беткән, ясалма тешләр белән файдаланды. Үпкә авыртуы белән шактый изаланды, бик күп вакытлар дәваланып уздырды. 1975 елның сентябрь аенда Казан больницасында вафат булды.

Әтиебез вафатыннан соң , әниебез шул нигездә гомер итте. Әтинең фотографиясең өстәл өстеннән алып куймады, гел күңеленнән аның белән сөйләшеп торды. Мин үзем шушы авылда кияүгә чыгып торганлыктан, гел әнием янына кереп, хәлен белеп, ярдәмләшеп тордым. Әнием белән күп очракта сөйләшү үткәннәрне искә алуга кайта иде. Сланцы шәһәреннән кайтып урнашкач ул әтием янында ат караучы ярдәмчесе булып эшләгән, аннан уракка йөрүләр, колхозга нинди эшкә чакырсалар, шунда барган. Пенсия яшенә җиткән булса да бер эшкә барудан калмаган. Ул чорларда балалар бакчасы булмаганлыктан, уракка йөри ала торган яшь балалы хатыннарның, балаларын бер зуррак өйгә җыеп караганнар. Безнең Гайшәбану әби дә бу эшләргә катнашкан. Балаларга ашарга пешереп торганмы, балалар караганмы – анысын гына тәгаен белмим. Гайшә әбинең әтидән башка ике кызы, ике улы булган. Киленең, безнең әнине бик яратып бетермәгәнгәдер, ул кышка Пермь шәһәренә, кызы Зәйнәпбануга китә иде. Киткәндә, кайтканда үзеннән алда үлемтек әйберләрен посылка белән җибәрә иде, мәрхүмә актык китүендә кайтырга әзерләнеп әйберләрен җибәргәч, кисәк кенә үлеп киткән. Әтием озатырга дип барганда, әбине җирләп, керләрен юып элгән булганнар.

Әтиемнең икенче сеңлесе – Фәхриямал шушы авылда яшәде. Җизнәбез – Гимадиев Гыйләҗтин, гомер буе терлекчелектә эшләде. Укый – яза белмәгән кеше, бозау карауда зур уңышларга ирешеп, хөкүмәтебез тарафыннан Ленин ордены белән бүләкләнде. Алар дүрт кыз үстерделәр: Гөлфирә белән Рәмзия бүгенге көндә Үзбәкстанда, Гөлсирә белән Минсара Татарстанда торалар.

Әнием иренең туганнары Әһлиулла белән Гатиатулланы гел искә ала иде. Бигрәк Әһлиулласының кызлары турында кызганып сөйли. Әһлиулла абыйның хатыны Гарифә апа, авылда яшәүче Мухамадиев Вагыйзнең әтисе Гариф абыйның апасы була, сугыш чорында поездда барганда үлә. Әниләре үлгәч, аның белән бергә булган ике кызны: Мөзәйнә белән Мөзәйтирәне поезддан төшереп, детдомга тапшыралар. Балалар үсеп җитә, кызларның берсе, тәгаен белмибез, туган язуындагы адрес буенча Иске Йөрек авылын эзләп кайта. Ул туганнарын табарга өметләнеп кайткандыр, тик ул вакытта идарәдә эшләгән кешеләр: “Туганнарыгыз юк, аларны табуда берничек тә ярдәм итә алмыйбыз”, дип кызны борып, туганнарын табуда өметен өзеп җибәрәләр. Моны үзләренчә яхшы ният белән эшләдек, чөнки сугыштан соң үзебезнең кешеләргә дә күп ярдәм кирәк, ә болар читтән кайтып утырсалар, никадәр булышасы була дип, аңлатканнар. Әнием, каһәр сугыш, кешенең туганнары белән аралашу хокукын да тартып алды бит, дип шул кызны кызганып елый иде.

Хәер, әниемнең бөтен тормышы, истәлекләре күз яше аша узды. Сланцы шәһәрендә җиде классны бетереп, Ленинград шәһәренең эретеп ябыштыручылар техникумына укырга киткән Самат абыебызны да гел сагынып яшәде. Абыебызны укып бетергәч, Иркутск, Чита якларына эшкә җибәрделәр. Киров өлкәсенең Березникиендә дә хезмәт куйды. Татарстанның Түбән Кама шәһәрендә гаиләсе белән торды. Язмыш җилләре аны Латвияга да илтеп ташлады. Самат абыебыз пенсиягә чыгып җитә дә алмыйча, туган иленнән ераакта, 1994 елны вафат булды. Ул безнең янга сирәк

кайта алды. Абыебыз кайткач барыбыз да әни янына җыела идек. Бөтен туганнар төрле җиргә сибелгән һәм аларның миңа теләгән теләкләренең берсе: “Бәлхия, син туган җирендә яшәп, бәхетле булсаң иде!”

Әтиебезнең тагын бер абыйсы – Гатиатулла. Аларның тормышы да җиңелләрдән булмый. Хатыны Әлимә апа үтә дә авыр тормышлы гаиләдән була. Аны абыйга хәер сорап йөргән җирдән, хатынлыкка алып калалар. Әлимә апа Балтач районының Шешеңгәр авылы тирәсендәге (тәгаен белмибез) авылдан була. Ул безнең авылда дүрт тәгәрмәчле кечкенә арба тартып хәер сорап йөргән. Шул арба тартып, тәгәрмәч тәгәрәтүеннән (катит), аны “кәти Әлимәсе” дип йөрткәннәр. Бик кызу, эшкә бик җиңел кеше булса да, бу кушамат күп еллар буе Әлимә апага тагылып килә. Аларның бер малай, ике кызлары була. Бер кыз балалары сабый чакта ук үлә. Уллары Ясәви Украинада тора, туган авылына сирәк кайта. Актык кайтуы - әнисе үлгәч, 1988 елда була. Шул вакыттан соң ул сеңлесе Мөсәвилә белән аралашудан туктый, бәлки моның сәбәбе аның укый – яза белергә өйрәнмичә калуындадыр. Мөсәвилә исә бөтен гомерен шушы авылда уздыра, гаилә кормый. Колхозда төрле эшләрдә эшли, терлекчелектә эшләп лаеклы ялга чыга. Туган авылы зиратына җирләнгән.

Әнием озын гомер гомерләде. Тормыш юлында күпме генә авырлыклар, югалтулар кичерсә дә әнием тормышны яратты, үзенең әйләнәсендәге һәр кешене тиешенчә үз урынлы күрде, үзенчә якын итте. Ул узган гомерен күз яшьләре белән искә төшерсә дә, беркайчан да язмышыннан зарланмады. Хөкүмәт түләгән әз генә пенсиясенә шөкер кылып, һәр яңа туган көнгә ихлас

сөенеп яшәде. Әнием 94 яшендә, 1998 елда үз нигезендә бакыйлыкка күчте.

Үзем инде олы яшьтәге кеше булсам да , әнине гел юксынып яшим. Аның белән кара – каршы сөйләшеп утырулар сагындыра, истәлекләр гел яңарып тора. Авылда җиде классны тәмамлагач, сигезенче классны укырга Малмыж шәһәренә бардым.

Көз көне укый башлагач, бер атна Татар Кунбашы авылында колмак җыйдык, бер атна Шешеңгәрдә бәрәңге алдык. Көзге эшләрдән соң ике атна укыгач ялларга өйгә кайттым. Өйгә кайтсам, әни авыртып тора, әтинең кәефе юк, миңа шул җитте – укырга бармаска карар кабул иттем. Тиз генә мондый уйга килүемнең сәбәбе бәлкем , үземнең дә бик укыйсы килмәведер. Шушы вакыттан, 15 яшемнән колхозда эшли башладым. Иң элек бригадир Мухамедзянов Файзелхак абый бәрәңге подвалына эшкә чыгарды. 17 яшемә кадәр төрле эшләргә йөрдем, аннан соң бозау карарга куйдылар. Әйбәт кенә эшләп йөргән көннәрнең

берсендә колхозның комсомол секретаре, ул вакытта яңа гына армиядән кайткан Мубараков Вагиз үз янына, сөйләшүгә чакырып алды. Ул миннән хайваннардан курыкмыйсынмы, дип сорады. Үзе теләгән җавапны ишеткәч, Мәдинә белән мал дәвалаучыга укырга барырсыз диде. Мәдинә, соңгарак аның тормыш иптәше булды. Мубараков Вагизнең киңәше белән без мал дәвалаучыга укырга киттек. Киров өлкәсенең Зуевск районында урнашкан Косино поселогында ветеринар фельдшерлар әзерләүче СПТУ №13 тә бер ел эчендә

һөнәр алдык. Чыгарылыш имтиханнар нәтиҗәсе белән шунда ук Уржум ветеринар техникумына, читтән торып укырга, документларны тапшырдык.

Бу техникумда дүрт ел укып, уңышлы гына тәмамлап, туган авылыбызда эшләдек.

Утыз биш ел хезмәт стажы белән лаеклы ялга чыктым.

Беренче никахым бик уңышлы булмады, күңелдә капма - каршылы хисләр тудырды. Ул бик кыска

вакытлы булса да, күп күз яше китерде. Ә тормыш иптәшем үз авылыбызның егете – Сагитов Габделхай. Без аның белән биш бала үстердек, дүрт кыз, бер малай. Үзенең вафатына уналты ел була инде. Өч кызыбыз авылда үз тормышлары белән, матур итеп балалар үстереп торалар. Һәрберсе күп итеп мал – туар асрап, тырыш хезмәт куеп яшиләр. Лилия кызым, гаиләсе белән Мәскәү өлкәсенең Дедовск шәһәрендә көн күрә. Улым Ришат үзенең урынын армия сафларында табып, контракт буенча хезмәт итә.

Бүгенге көндә мин тормышымнан бик кәнагать, уңайлыклары булган үз өем бар. Балаларым, туганнарым белән аралашып яшим: Фагыйлә апам, тазалыгы какшаганлыктан Түбән Кама шәһәрендә балалары янында, ә Фәния сеңлем Арчада тора. Тормышымны үзем белә башлаган вакыттан искә төшереп, күп вакыйгалар хәтердән чыккан, уйлап утырган чакларда, илебездәге тормышның никадәр каршылыклы, авыр, газаплы, кайбер чорлары никадәр мәгьнәсез булганлыгы өнсез калдыра. Синең язмышын бәхетлеме дигән сорауга, минем, әниемнең, кыз туганнарымның, үземнең, кызларымның язмышын күздә тотып, авылдашыбыз Асхадуллина Разия апа сүзләрен китерәсем килә:

Кыз баласы булган кеше
Кадерләсен баласын.
Ул белсен, кыз баласының,
Кадерсезгә каласын.

Судьбы печальной отголоски : воспоминания / сост. Е. Н. Касимова, ред. М. Т. Хасанова. – Малмыж : МКУК Малмыжская ЦБС, Староирюкская СБФ – центр татарской культуры им. Г. Тукая, 2017. – 24 с. – (В Победе их немалая заслуга).

Выпуск издания реализован в рамках проекта «Живая легенда». Финансовая поддержка проекта осуществлена благотворительным фондом «Хорошие истории» в рамках программы «Активное поколение».

Муниципальное казенное учреждение культуры
Малмыжская централизованная библиотечная система
Староирюкская сельская библиотека – филиал № 29
Центр татарской культуры им. Г. Тукая
Адрес:
612941, Кировская область, Малмыжский район,
село Старый Ирюк, ул. Садовая, дом 2-а;
Дом культуры, 2-й этаж
casimova.lena2015@yandex.ru